КАЙГЫРТУ

Аз санлы милләт вәкилләренә туган телне саклау тагын да катлаулырак

> 2

РАМИЛ ӘЙБӘТОВ:

«Миңа монда начар эшләргә ярамый. Чирмешән – минем туган җирем»

> 3

КҮМЕР КИРӘК!

«Бер нәрсәгә дә ышаныч булмый. «Җилкәнсезләр»дә дә – шул ук хәл»

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөртекләр – бирегә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 92 (29059) | Шимбә | 1 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ИСЕМЛЕ ЭШ ТАРКАЛМАС

Өйдә акчага пилмән бөгү, бизәндерү, кием-салым тегү белән шөгыльләнүчеләргә сөенче бар. Бу атнада үзмәшгульләргә товар билгесен теркәргә рөхсәт итүче яңалык гамәлгә керде. Бүген республикада 260 меңгә якын кеше үз көнен үзе күреп яшәвен исәпкә алсаң, Татарстанда җитештерелә торган брендлар саны кискен артып китмәгәе. Товар билгесен алу җиңелме? Ул ни бирә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга ачыклык кертте.

Яшел Үзәндә яшәүче Рамилә Гарифуллина – үзмәшгуль. Ул муслин тукымадан балаларга киемнәр тегә.

– Мин – белемем буенча дизайнер. Тегүче булып эшләү тәҗрибәм дә бар. Үз юлымнан китәргә теләп, бер ел элек үзмәшгуль буларак теркәлдем. Хәзер өйдә муслин тукымадан балалар өчен киемнәр, сабыйларга урын-җир кирәк-яраклары тегәм. Якын арада маркетплейска да чыгарга телим. Тик интернет-мәйданда фотоларны урнаштыргач, башкалар да минекенә охшаган киемнәр тегә башлаячак дип шикләнәм. Товар билгесен алу турында уйланганым бар. Тик өйдә утырып, бу кадәр зур эшкә тотынырга да куркыта, – ди үзмәшгуль.

Бу атнада Россия Гражданнар кодексына үзгәрешләр керттеләр. Аның нигезендә, үзмәшгульләргә товар билгесен теркәү мөмкинлеге бирелде. Моңарчы исә мондый хокуктан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр генә файдалана алды. Ил күләмендә гамәлдә булачак товар билгесе алу өчен 21700 сум акча түләргә кирәк.

– Мондый закон әлегә кадәр булмаганлыктан, миңа дүрт ел элек җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять ачарга туры килде дә инде, – ди «TatarsCarf» брендына нигез салучы Елена Габдрахманова. – Без милли бизәкле татар яулыклары җитештерәбез. Бүген рәсми рәвештә теркәлгән ике товар билгебез бар. «TatarsCarf» исеме белән бер рәттән, үз шигаребезне дә бренд иттек. Хәзерге вакытта тагын ике товар билгесен рәсмиләштерү белән шөгыльләнәбез. Ул башка юнәлештәге бик зур проектлар булачак. Ләкин әлегә алар хакында сөйли алмыйм. Товар билгесе әзер булганны көтәбез. Үз эшен башлап җибәрүчеләргә әйтергә теләгән фикерем дә шул: иң элек теге яки бу продукциягә товар билгесен алырга, ә аннары гына аны сатуга чыгарырга кирәк. Без дә башта милли бизәкле татар яулыкларын брендсыз гына сата башладык. Күп тә үтмәде, безнекенә охшаган ялган товарлар күпләп пәйда булды. Шуннан соң үз брендыбызны рәсмиләштерергә мәҗбүр булдык. Дөреслектә исә эшне кирәдән башларга кирәк иде. Тиешле таләпләрне дөрес үтәгәндә, товар билгесен алуның бернинди кыенлыгы да юк. Мин аны артык кыйммәт дип тә әйтмәс идем. Әлеге төр хезмәтнең бәясе кемгә мөрәҗәгать итүеңә, документны электрон яки кәгазь рәвештә алуыңа да бәйле. Мин үзмәшгульләр өчен бик шат. Бу – үз эшеңне җәелдерү өчен яхшы мөмкинлек. Киләчәктә кирәкмәсә, товар билгесен сатып җибәреп тә була бит. Шул ук вакытта, аңа артык зур өметләр бағларга да кирәкми. Безнең милли бизәкләрне элек ничек урлап маташсалар, бу хәзер дә шулай. (*Көлә*). Аермасы шунда: без хәзер юридик яктан тулысынча яклангән.

Билгеле булганча, үзмәшгульләргә тәҗрибә рәвешендәге махсус салым режимы 2019 елда илнең дүрт төбәгендә, шул исәптән Татарстанда гамәлгә керде. 2020 елның 1 гыйнварыннан аны илнең тагын берничә төбәгендә, ә соңрак ил күләмендә дә җәелдерделәр. Үзмәшгуль буларак теркәлүче физик затлар эшләүдән, хезмәт күрсәтүдән, товар сатудан кергән акчадан – 4, шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар 6 процент күләмендә салым түли. Әлеге төр эшчәнлеккә кучүчеләр 13 процент күләмендә керем өчен түләнүче салымнан азат ителә. Үзмәшгульләр арасында кием-салым тегүчеләр, балалар өчен продукция җитештерүчеләр һәм ашсу осталары күбрәк.

Хәзер һөнәри керемгә салым түләүчеләр шәхси эшмәкәрләр белән көндәшлек итә алачак, ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин.

– Үзмәшгульләргә яңа мөмкинлекләр ачыла. Чөнки товар билгесе – ул, иң беренче чиратта, ышаныч дигән сүз. Гап-гади мисал: кибеттә күмәч сатып алганда да: «Бу кайсы ипи заводыныкы икән?» – дип кызыксынабыз бит. Ышанычлы товарны алырга теләүчеләр артачак. Димәк, бүгенге үзмәшгульләр иртәгә эшкуар дәрәҗәсенә үсеп җитәргә дә бик мөмкин. Чит ил брендлары илдән чыгып киткәч исә базарда һәркемгә урын җитәрлек, – ди белгеч.

Үзмәшгульләр арасында үз брендын булдырырга теләүчеләр күп булачагына да шикләнмиләр. «Роспатент» мәгълүматларына караганда, быелның биш аенда гына да аларга товар билгесе алуга бәйле 47 меңгә якын гариза килеп ирешкән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу – 23 процентка күбрәк. Татарстан Рәисе каршындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил аппаратының матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, алар республика үзмәшгульләре арасында аңлату эшен башлаган инде.

Таңсылу Галимова

Фикер

Евгений БЕЗРОДНОВ, Татарстан бизнес-омбудсменының иҗтимагый кабул итү бүлмәсе җитәкчесе:
– Татарстанда 260 меңнән артык кеше үзмәшгуль буларак теркәлгән. Эш өчен шартлар тудыру күзлегеннән чыгып караганда, товар билгесен алу һөнәри керемгә салым түләүчеләрне юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр белән бер дәрәҗәгә күтәрәчәк. Иң мөһиме, үзмәшгульләрнең эшчәнлеге (товар билгесе, бренды) юридик яктан якланачак. Өстәвенә лицензияләнгән килешү нигезендә товар билгесенә хокукны башкаларга биреп торудан керем алырга да мөмкин булачак.

Өстәмә балл

Югары уку йортларына укырга кергәндә, махсус операциядә катнашкан абитуриентларга өстәмә баллар кушарга мөмкиннәр. Бу хакта Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы башлыгы урынбасары Дмитрий Афанасьевның рәсми хатында әйтелә.

«Бакалавриат һәм белгечлек (специалитет) программалары буенча укырга кергәндә чакырылыш буенча хәрби хезмәт, шулай ук контракт буенча хәрби хезмәтне, Россия Кораллы көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәтне узу, махсус хәрби операция барышында Россия Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә иректе катнашу кебек шәхси казанышлар исәпкә алыначак», – диелә рәсми документта.

Шәхси казаныш буларак 10 баллга кадәр өстәргә тәкъдим ителә.

Биш айга – 72 очрак

2023 елның биш аенда республикада кызамык чиренең 72 очрагы теркәлгән. Узган елның шушы чорында бер генә кеше авырган. Бу хакта Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина хәбәр итте.

«2021 елда кызамык Россиянең 17 төбәгендә теркәлде, 109 очрак ачыкланды. Узган ел 66 субъектта әлеге авыруны йоктыручылар саны 3925 кешегә җитте. Татарстанга килсәк, 2022 елда кызамык йоктыруның – бер, бу елның биш аенда 72 очрагы теркәлде. Шуларның 32се – балаларда», – диде ул.

Идарә башлыгы сүзләренчә, авыру ешрак Таҗикстаннан, Кыргызстаннан килгән кешеләр арасында, шулай ук әлеге чирдән прививка ясатмаган кешеләр арасында очрый.

Марина Патяшина вакцина ясату турында да искә төшерде. Аның әйтүенчә, балага 1 яшьтә вакцина ясыйлар, ә 6 яшендә ревакцинация үткәрәләр. Хәзерге көндә Татарстанда вакцина җитәрлек булуын ассызыклады идарә җитәкчесе.

Егетләргә ярдәм

Татарстан мөфтияте махсус хәрби операция зонасына республикадан мобилизацияләнгән солдатларга гуманитар йөк алып барырга ниятли. Бу хакта Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте хәбәр итә.

Моңа кадәр мөфтият вәкилләре Луганск өлкәсе юнәлешендәге хәрби частьларның берсенә ике тапкыр командировкага барып кайткан иде. Бу бүлекнең 90 процентын Биектау, Питрәч, Саба, Арча, Балык Бистәсе районнары һәм Казаннан килгән Татарстан егетләре тәшкил итә. Шуларның 50се – дин нигезләрен үтәп яшәүче мөселманнар.

Татарстан мөфтияте делегациясе җыйган йөкне турыдан-туры солдатларның үз кулларына тапшыра. Мөфтият вәкилләре барлык битараф булмаган кешеләрне хәрбиләргә кирәк-яраклар сатып алу өчен акча җыярга чакыра. Егетләргә ярдәм итү өчен үз өлешен һәркем кертә ала. Акчаны Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды җыя.

Хәзерге вакытта махсус хәрби операциядәге егетләргә рация, повер-банк, дарулар, бинт, оекбаш, хәләл тушенка, коры паеклар һәм башка азык-төлекләр кирәк.

Яңалык

Июль ае үзгәрешләре

Илдар Мөхәммәтҗанов

✓Хәзер хакимият кайбер дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен бердәм стандарт булдыру хокукына ия. Аерым алганда, мондый бердәм стандарт өч төрле хезмәт өчен каралган: **балага пособие билгеләү, россиялеләрнең аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарын, шулай ук балалар бакчасы өчен ата-аналар түләүен компенсацияләү**. Бу хезмәтләрдән файдалану өчен Дәүләт хезмәтләренең бердәм порталына мөрәҗәгать итәргә була. Гариза биргәндә аерым документлар җыю таләп ителми.

✓Баллы газлы суга акциз кертелә. Аның хакы – 1 литрга **7 сум** булачак. Акциз шикәр күләме 100 миллилитрга биш граммнан артык булган эчемлекләргә салыначак. Шунысын да искәртергә кирәк: ул куас, сок һәм морсларга салынмый.

✓Микрофинанс оешмаларны авызлыклаячаклар. Кыска вакытлы кулланучылар кредиты буенча көндәлек процент ставкасының максималь дәрәҗәсе **1 проценттан 0,8 процентка** кадәр киметеләчәк. Шушы ук закон кулланучылар кредитына да кагыла. Ставканы 365 проценттан 292гә калдырачаклар. Шулай ук закон нигезендә, исәпләнгән штраф, пеня һәм башка өстәмә түләүләр кредит суммасыннан 130 процентка артмаска тиеш дигән чик тә куела.

✓Дәүләт хезмәтләре порталына **аттестат һәм дипломны** урнаштырып булачак. Порталдагы документларны югары уку йортына кергәндә, эшкә урнашканда кулланырга мөмкин.

✓Сәламәтлек саклау министрлыгы психик һәм үз-үзен тотышында тайпылышлар булганда **медицина ярдәме күрсәтү тәртибен** үзгәртте. Яңа таләп буенча, мондый ярдәмне медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга тиешле лицензиясе булган дәүләт, муниципаль һәм шәхси сәламәтлек саклау системаларының медицина һәм башка оешмалары күрсәтергә тиеш.

✓15 июльдән **ОСАГО буенча юл-транспорт һәлакәтләрен электрон рәвештә рәсмиләштерергә** мөмкин булачак.

✓Мөмкинлекләре чикле балалар тәрбияләүче ата-аналарга **адвокат хезмәте** бушлай тәкъдим ителәчәк. Юристларга консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

✓**Эшсезлек буенча пособие** алу өчен уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзгәрә.

✓**Хәмер эчеп рульгә утырганнарны тикшерү** шаһитлар катнашында узачак. Шулай ук тикшерү вакытында видео төшерү дә каралган.

Сүзгә-сүз



Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Үз сәүдә маркаларыбызны булдыру һәм таныту өчен, Россия җитештерүчеләренә ярдәм итәргә кирәк. Алар белән илдә генә түгел, дөньяда да горурланырлык булсын. Безнең компанияләр һәм командалар көндәшлеккә әзер. Күбесе моны исбатлады инде. Компанияләр чит илнекеннән калышмый торган бик яхшы характеристикалы продукция җитештерә.

(«Яңа заман өчен көчле идеяләр» форумыннан)

ТАТАРСТАНДА – ЯШЬЛӘР

2023 ел башына Татарстанда яшәүче яшьләр саны 1,046 млн кешене тәшкил иткән. Искәртик: яшьләр категориясенә 14–35 яшьлекләр керә.

Шәһәрләрдә **813,4 мең** яисә **77,7%**



Авылларда **233,2 мең** яисә **22,3%**

Татарстанстат мәгълүматлары буенча

Яшенле яллар

Июль башы Татарстанга яңгыр, яшен, җил һәм эссе һава торышы алып киләчәк. Татарстан Гидрометеоүзәге шул хакта хәбәр итте.

Шимбә, 1 июльдә, кыска вакытлы яңгыр, урыны белән яшен дә булыр дип көтелә. Төнге температура 13–18 градус җылы булса, көндез 22–27 градус булачак.

Якшәмбе һава торышы үзгәрәчәк. Шулай ук яшенле яңгыр, җил көчәю көтелә. Һава торышы төнлә – 11–16, көндез 22–27 градус җылы булачак.

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Вакыт галиҗәнаплары,
яки Сфинкс ник елмая?

Ул кайчакта җитми. Ә кайчакта узмый интектерә. Аны әле кайчакта «үтерәләр» дә. Сүз вакыт дигән әйбер, категория турында иде. «Үтерәләр» дию шуннан, рус телендә «убить время» дигән кәлимә бар бит. Вакытның асылы шунда: тирә-ягыбызда ни-нәрсә бар, барысы да туктаусыз үзгәрештә. Үзебез дә үзгәрәбез. Җиһанда фотографиядән башка катып калган бер нәрсә дә юк, була да алмый. Шул үзгәрешләрне, хәрәкәтне без вакыт дип кабул итәргә, атарга күнеккән.

Безне урап алган тирәлектә хәтта тик торган җисемнәр дә хәрәкәттә. Беренче карашка мәңгелек кебек тоелган гранит таш кыялар да үзгәреп тора – алар да тузу, чатнау, ваклану, убылу юлында. Аерма бары шунда: аларның гомере кеше гомере белән чагыштырганда күпкә озынрак.

Берсендә мәктәптә бер чорда укыган, берничә дистә еллар күрмәгән яшьтәш, замандаш «кыз»лар очрады. «Чәчәк кебек кызлар идегез, кай арада мондый юан әбиләргә әйләнергә өлгердегез?» – дигәнемне сизми дә калдым. Ярый, ачуланмадылар тагын. Ә бит аз гына да арттырмадым. Очрашканчы алар минем өчен чыннан да камыштай нәзек, сылу гәүдәле, бармак күрсәтсәң дә көлә торган чыркылтык кызлар иде. Ә хәзер… Вакыт рәхимсез. Җан ияләренә карата бигрәк тә. Ташбакалар, тутый кошларның кайбер төрләре йөз-йөз илле ел яши, диләр. Бер үк вакытта гомере нибары бер яисә берничә көн булган күбәләкләр барлыгы да билгеле. Андый җан ияләренең шунысы яхшы: аларга фикерләү, сәгатьләрне, көннәрне, елларны санау сәләте бирелмәгән. Бер гасыр яшиме, бер көнме, яралалар, нәсел калдыралар һәм юкка чыгалар. Шул ук күбәләккә бер көн, бәлки, олы бер гомер булып тоеладыр. Вакыт агышы төрле җан ияләре өчен төрлечә, диләр бит.

Кеше заты – үзенең гомере чикле икәнен белүче бердәнбер җан иясе. Шулай да пошаманга төшеп йөрүче юк. Киресенчә, күп кеше дөньяга мәңгегә килгән кебек кылана. Ә яшь чакта, гомумән, диңгез тубыктан, оптимизм мөлдерәмә. Күпсанлы немец философларының берсе – Шопенгауэр дигәне язып калдырганча: «Яшьлек күзлегеннән караганда, алда – бетмәс-төкәнмәс киләчәк. Олыгайгач, артка борылып карыйбыз да бик кыска үткәнне күрәбез». Ягъни «Яшьлекнең дә мәңге, мәңге булырына ышанмадыкмыни, ышандык. Ә нигә соң синең күзләреңдә көзләр нуры сеңгән уйчанлык?» Гомернең кыскалыгына иртәме, соңмы һәркем дә төшенә – вакыт үтү, «көзгә керү» генә кирәк.

«Вакыт пирамидалардан курка», – дигән гыйбарә бар. Янәсе, мең ел үтә, ике, өч мең ел – шәһәр чаклы шәһәрләр, халыклар, цивилизацияләр юкка чыга, ә Хеопс пирамидалары, алар янындагы тылсымлы елмаюлы таш сфинкс – адәм чырайлы, арыслан гәүдәле сын гына, артларына да әлмичә, ничек торган булса, шулай тора бирәләр. Ирексездән Гамил Афзал шигыре искә төшә:

Сфинкс елмая, таш йөздә киная,
Карашы мыскыллы, янаулы:
«Күрегез, мин монда дүрт мең ел елмаям,
Ә сезнең сәгатьләр санаулы…»

Бик үк алай түгел шул менә, ул да акрын гына җимерелә. Вакыт пирамидалар өчен дә рәхимсез. Аерма шунда: бәндә гомере еллар белән үлчәнсә, пирамидалар белән сфинксныкы – гасырлар белән. Яңадан ике-өч, күп булса, биш мең ел – пирамидалардан да ком өеме генә калачак. Биш мең ел кеше гомере белән чагыштырганда, әлбәттә, коточкыч олы вакыт аралыгы. Тик миллиард еллар яшәүче галәм өчен ул да мизгел генә.

Без барыбыз да – туктаусыз, алсыз-ялсыз үткәннән киләчәккә баручы сәяхәтчеләр. Туктаусыз, дию шуннан, вакыт туктый белми. Тик торсаң да, ятып йокласаң да, алга бара. Ул чәчәктәй яшь кызларны гыйшык утында яндыра, кияүгә бирә, бераздан ана итеп куя, кырыкны узуга йөзгә беренче җыерчыкларны сыза. Диеталарга, дөрес туклануга, сәламәтлек турында туктаусыз кайгыртуга да карамастан, кеше вакытны алдый алмый, ул үзенекен эшли – иртәме, соңмы, оныкларны сөяр вакыт җитә, Ходай насыйп иткәндә – аларның балаларын. Тик күпләр сиземләгәнчә, яшь арткан саен вакыт агышы тизәя. «Яңа гына таң ата, борылырга да өлгермисең, кич җиткән була». Өлкәннәр авызыннан шактый еш ишетелүче сүз бу. Биредә янә Шопенгауэр искә төшә. «Баланың бер сәгате карт кешенең бер көненнән озынрак». Бу гыйбарәне, аның дөреслеген белгәнгә, күренешнең асылын үземчә аңларга озак тырышып йөрдем. Аз-маз аңладым да кебек. Тик менә төгәл аңлатманы философ үзе язган булып чыкты. Бала чакта, яшь чакта кичерешләр күп һәм тирән, чөнки син дөньяны танып белә башлаган гына әле. Ә өлкән кешене берни белән дә шаккатырып булмый, ул инде барысын да күргән. Марсель Галиев әйтмешли, аның өчен «Җир шары да түбәтәйдәй гади бер нәрсә». Бәс шулай икән, акыл, интеллект күренешләр, вакыйгалар өстеннән шуып кына үтә, тоткарланмый – кичерешләр йә юк, йә бик аз. Вакыт та шул сәбәпле кыска тоела, аның әһәмияте кими…

Вакыт дигән категориягә кагылгач, тагын бер күренешкә игътибар итәсе килә. Без вакыйгалар куерган, мәгълүмат башка ишелеп торган заманда яшәп ятабыз. Алга барган саен андый ашкынлык арта гына торачак. Дөнья куу да шундый темпта, күп кешегә хәзер вакыт җитми. Шәһәрдән шәһәргә элекке чорлардагы кебек атта түгел, автомобильдә, хәтта самолетта барышлы югыйсә. Керне, табак-савытны машина юа. Элекке кебек өстәл янына утырып озын хатлар язу да бетте, аларны ике җөмләдән торган смс хәбәр алыштырды. Ә аралашырга, яратырга, кунакка йөрешергә вакыт юк. Вакыт кая югала соң?

Миңа калса, безне нәфес харап итә. Без тормыштан, кибетләрдән барысын да алып калырга тырышабыз, күсе кебек үзебезгә җыябыз. Күпме җыйсак та, аз. Каударланып тагын чабабыз. Барын да алып булсын өчен икешәр эштә эшлибез. Балалар дигәндә дә без хәзер тәрбиячеләр түгел, ә тәэминатчылар – нәрсә сорый, шуны алып бирәбез дә аның күңеле турында онытабыз. Дөнья куу безне иртәдән кичкә кадәр чабучы күзе тонган робот итә. Кая ул онытылып, озаклап кичке шәфәкъ белән хозурлану, күршеңә кереп кич утыру, бала белән дөнья онытып аралашу. Алай эшләгәндә вакыт әрәм була бит, вакыт ул, янәсе, акча… Болай кылануларда вакыт дигән категориянең гаебе юк, дию генә аз. Бу – бары безнең очсызлану, әйләнеп кайтмас вакыт галиҗәнапларының кадерен белмәү, аны очсызлы кыйммәтләргә сарыф итү генә…

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Чаллыда «Ростех» дәүләт корпорациясе генераль директоры Сергей Чемезов җитәкчелегендә узган «КАМАЗ» ГАҖ Директорлар советының чираттагы утырышында катнашты. «Чарада агымдагы елның биш аенда башкарылган эшкә йомгак ясалды. Көн тәртибендәге төп мәсьәләләрнең берсе – компаниянең Директорлар советы рәисе сайланды. Әлеге вазыйфага «Ростех» дәүләт корпорациясе генераль директоры Сергей Чемезов билгеләнде», – дип хәбәр иткәннәр «КАМАЗ»ның рәсми сайтында.

Чаллыга эш визиты кысасында, кунакларга йөк машиналарының яңа модельләрен дә күрсәткәннәр. Рөстәм Миңнеханов уртача тонналы «Компас» йөк машинасында йөреп тә карады. «Зур булмаган йөкләрне ташу өчен шәп машина», – дип фикере белән уртаклашты ул социаль челтәрдә.

tatarstan.ru

КИЛӘЧӘКНЕ УЙЛАП

Республикада җиңел атлетика киләчәге турында фикер алышу, әйдәп баручы белгечләр белән очрашу, инновацияле проектлар белән танышу… Республика Рәисенең кичәге эш көндәлеге әнә шундый вакыйгалардан гыйбарәт иде.

Рөстәм Миңнеханов иң элек Монополиягә каршы федераль хезмәт җитәкчесе урынбасары, Бөтенроссия җиңел атлетика федерациясе президенты Петр Иванов белән очрашты. Очрашуда 2028 елга кадәр Татарстанда җиңел атлетиканы, массакүләм йөгерү хәрәкәтен үстерү, шулай ук җиңел атлетика инфраструктурасын камилләштерү буенча программаны гамәлгә ашыру турында фикер алыштылар.

Очрашу димәктән, Татарстан Рәисе аддитив технологияләр өлкәсендә илебезнең әйдәп баручы белгечләре белән дә күреште. Анда әлеге төр технологияләрне үстерү мөмкинлекләре, Казанда аддитив технологияләр буенча бөтенроссия форумын үткәрү турында фикер алыштылар.

Алдан ук ачыклык кертеп китик: аддитив технологияләр – материалны катламлап кушу юлы белән өч үлчәмле объектлар һәм детальләр булдыру процессы ул. Моның өчен 3D принтерлар кулланыла. Бүген аддитив технологияләр авиа һәм двигатель төзелешендә, автосәнәгатьтә, космик сәнәгатьтә, суднолар төзүдә һәм башка тармакларда кулланыла.

Әлеге төр технологияләрнең әһәмияте турында «Татнефтехиминвест-холдинг» акционерлык җәмгыяте Директорлар советының чираттагы утырышында да сөйләштеләр. Утырышны Рөстәм Миңнеханов уздырды. Аддитив технологияләрне үстерү ассоциациясенең башкарма директоры, «ТВЭЛ» акционерлык җәмгыяте президенты киңәшчесе Ольга Оспенникова сүзләренә караганда, 2030 елга аддитив технологияләр базары 72,5 млрд долларга кадәр үсәчәк. Бу вакытка Россиядә әлеге күрсәткечне 13 млрд сумга җиткерү планлаштырыла.

Утырышта тагын берничә инновацияле проект тәкъдим ителде. Әйтик, «РусАТ» җәмгыяте якын киләчәктә зур әйберләрне турыдан-туры лазер белән үстерү өчен Россиядә беренче роботлаштырылган җайланма чыгара башлаячак. Автоматлаштырылган күчмә төзекләндерү комплекслары эшләнгән. Оешманың генераль директоры Илья Кавелашвили сүзләренә караганда, аларны ерак урыннарда, мәсәлән, Арктикада нефть һәм газ объектларында кулланырга мөмкин булачак.

Санкт-Петербург диңгез техник университеты ректоры Глеб Туричин биметалл детальләрне турыдан-туры лазер белән үстерү турында сөйләде. Ул атом энергетикасында һәм ракета төзелешендә зур габаритлы җайланмалар чыгару өчен кирәк. Глеб Туричин Татарстанда аддитив технологияләр үзәге ачарга да тәкъдим итте.

Утырыш барышында Рөстәм Миңнехановны «Татнефтехиминвест-холдинг» Директорлар советы рәисе итеп сайладылар. Холдингның генераль директоры итеп Рафинат Яруллин расланды.

Җинаятькә тиң

Барча мөселманнар Корбан гаетен каршылаган көндә тетрәндергеч вакыйга булды. Швециянең Стокгольм шәһәре үзәгендә Коръәнне яндырдылар. Россия Президенты Владимир Путин бу акцияне җинаять дип атады.

– Бу – мөселманнарның Изге китабы һәм ул башкалар өчен дә изге булырга тиеш. Без башка илләрдә башкача эшләүләрен – кешеләрнең дини хисләрен хөрмәт итмәүләрен һәм моны җинаятькә санамауларын беләбез. Безнең илдә исә бу – җинаять. Конституция буенча да, Россия Җинаять кодексының 28 нче маддәсе буенча да җинаять санала. Конфессияара ызгыш китереп чыгару бу, – дип белдерде Путин Дагыстанның Дербент шәһәрендә узган киңәшмәдә.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та әлеге башка сыймаслык акциягә бәйле рәвештә фикерен белдерде.

– Бөтен дөнья мөселманнары өчен мөһим булган бу көннәрдә без яңадан Изге Коръәннең коточкыч мәсхәрә ителүенә шаһит булдык. Мондый вандализм гамәлләренең даимигә әверелүе һәм хакимиятләрнең рәсми рөхсәте белән узуы тирән борчуга сала, – ди Татарстан Рәисе. – «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе буларак, мин бу кешелексез гамәлне җитди гаеплим. Әгәр дә аларның Конституциясе кайдадыр яндырылган булса, Швеция хакимияте нишләр иде икән?

Рөстәм Миңнеханов белдерүенчә, Россиядә Президентыбыз тырышлыгы белән барлык дин вәкилләре тыныч һәм тату яши.

– Президентның Россиядә Коръәнне хөрмәт итмәү – җинаять дигәнныклы позициясе исламга тирән хөрмәт күрсәтүнең ачык дәлиле. Ә христиан һәм мөселман кардәшләренә карата үзара хөрмәт һәм мөнәсәбәт Россия халкының бердәмлеген ныгыта. Миллионлаган мөселман бу бәйрәм көннәрендә бер үк вакытта бердәмлек, тынычлык һәм акыл бөтенлеге өчен дога кыла дип ышанам, – диелә Татарстан Рәисе белдерүендә.

Яме китмәсен

Көтеп алган җәйге ял тыныч кына узсын өчен, алдан аяк киенергә кирәк. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марина Патяшина шулай ди. Бигрәк тә чит илгә ялга җыенучыларга аеруча игътибарлы булырга киңәш итә ул.

Идарә башлыгы сүзләренә караганда, ял итәргә барыр алдыннан иң элек шул җирлектә нинди инфекцияләр барлыгын алдан белешергә кирәк. Бу хакта турагентлар да кисәтергә тиеш.

– Кайбер илләргә керү чикләнгән. Мисал өчен, әгәр сезнең сары бизгәккә каршы прививкагыз булмаса, Африканың 32 иленә, Көньяк Американың 12 иленә керү тыела. Әлеге прививканы бер тапкыр ясатсаң, ул гомер буена җитә. Аны ясату турында халыкара сертификат бирелә. Шушы документтан башка бу илләргә керү тыела, – дип сөйләде Патяшина журналистлар белән очрашуда. – Кайбер илләргә барыр алдыннан вакцина ясау мәҗбүри түгел, әмма киңәш ителә. Менингококк инфекциясе, вируслы А гепатиты яки тиф авыруына каршы ясала торган прививкалар шундыйлардан. Кайбер илләргә барыр алдыннан малириягә каршы дарулар эчәргә кирәк. Әлеге чирне черкиләр тарата.

Марина Патяшина китергән мәгълүматлардан аңлашылганча, чит илдә ял итеп кайтучылар күбрәк нәкъ менә черкиләр йоктырган авырулардан зыян күрә икән. Малириядән тыш Денге авыруы да шул рәвешле тарала. Соңгы алты елда Татарстанда әлеге чирне йоктыруның 17 очрагы теркәлгән. Аны, нигездә, Танзания, Руанда, Гана белән Чад Республикасы кебек җирләрдә ял иткән кешеләр алып кайткан.

– Хәзерге вакытта 300 мең кеше шундый тикшеренү узды. Шуларның 12сенең ял иткәндә авыру йоктырганлыгы ачыкланды. Төгәлрәк әйтсәк, аларның дүртесе – эчәк инфекциясе, өчесе – җил чәчәге, калганнары инфекцияле булмаган авыру йоктырган, – ди Патяшина.

Ял иткәндә йоктырырга мөмкин булган чирләр үзебездә җитәрлек анысы. Белгечләр табигатьтә ял иткәндә аеруча сак булырга киңәш итә. Ел башыннан бирле Татарстанда талпан кадалган 22 кешедә боррелиоз авыруы ачыкланган. Мөслим районында яшәүче 5 яшьлек балага талпан энцефалиты диагнозы куелган. Билгеле булганча, әлеге чир кешенең үзәк нерв системасын зарарлый, ул хәтта инвалид калырга мөмкин.

Елның елында җәй көне эчәк инфекциясе очраклары да арта. Гади генә итеп әйткәндә, юылмаган куллар авыруы бу. Шуңа күрә белгечләр җәен шәхси гигиена кагыйдәләре турында да истән чыгармаска киңәш итә.

Күбебезнең иң яраткан сые – шашлык пешерүнең дә рәте бар. Марина Патяшина бу эшкә дә җаваплы карарга киңәш итә.

– Шашлык пешергәндә, нигездә, тавык итенә өстенлек бирергә кирәк. Учактагы ит пешеп бетмәгән булса, кеше сальмонеллез авыруы йоктырырга мөмкин. Шуңа күрә шашлыкны дөрес итеп пешерергә кирәк. Шашлыкка дигән итне ышанычлы җирдән генә сатып алу зарур. Аны үзең маринадласаң яхшырак, – ди ул. – Кибеттә сатыла торган әзер күмердән дә читтә торырга киңәш итәр идем. Ул эшне шактый җиңеләйтә, билгеле. Әзер күмерне саласың да шашлык ярты сәгать дигәндә пешеп тә чыга. Ләкин сатып алынган күмернең составында бензопилен дигән зарарлы матдә күп. Ул шашлыкка да сеңә. Шуңа күрә шашлыкны утын яндырып әзерләнгән күмердә пешерсәң яхшырак.

КЕЧКЕНӘ ТҮГЕЛ, ҺӘРКАЙСЫ – ЗУР ХАЛЫК!

КУКМАРАДА ТУГАН ТЕЛЛӘРНЕ САКЛАУ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШТЫЛАР

И туган тел!

Үзәктә – мари һәм удмуртлар. Кукмарада узган республикада яшәүче милләт вәкилләренең туган телләрен саклау мәсьәләләренә багышланган семинар-киңәшмәдә нәкъ менә әлеге ике милләтнең телләрен, мәдәниятен үстерү өчен тиешле шартлар булдыруга басым ясалды. Комиссия вәкилләре, без аларга ничек булыша алабыз, дигән сорауга җавап табарга тырышты.

– Һәр милләт үзен сакларга тырышырга тиеш. Без, татарларга җиңел түгел, дип зарланабыз, ә бик аз санлы булган милләт вәкилләренә туган телен, традицияләрен үстерү, саклау тагын да катлаулырак, – диде Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе җитәкчесе Марат Әхмәтов.

Ул сүзне соңгы җанисәп нәтиҗәләреннән башлады. Әйтик, республикада яшәүче удмуртлар санының исәбе алдагы халык санын алганда 23 мең булса, хәзер – 21 мең. Тик удмурт халкы белән вазгыять уңайрак икән әле. Ике җанисәп арасында марилар 19 меңнән 16 меңгә калган. Чарада катнашучыларның күбесе үз районнарында чуаш, мордва, удмуртларның кимүен әйтте. Балтач, Менделеевск районнарында гына вазгыять яхшырак. Балтачта – марилар, Менделеевскида удмурт халкы күбәйгән.

– Җанисәпнең икенче борчулы ягы – туган телләрен белүчеләрнең саны кимү. Без бүген туган телләрне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау һәм аны яшь буынга тапшыру юлларын эзләү өчен җыелдык, – диде Марат Әхмәтов.

Республикада төрле милләтләрнең 250дән артык фольклор коллективлары бар. Марат Әхмәтов, күләгәдә калмасын өчен, аларны район башлыкларына төрле чараларда активрак катнаштырырга кирәклеген искәртте. Җитәкчеләргә әйтер сүзе бу гына түгел иде аның.

– «Татар сүзе» бәйгесендә милли телләр өчен дә номинация булдырдык. Хәзер анда районнарның ни дәрәҗәдә актив катнашуын күзәтәчәкбез. Бүген безнең комиссия чуаш, удмурт, мордва, мари телләре буенча конкурс үткәрү өчен оештыручылар эзли. Без чыгымнарны тулысынча капларга әзер. Удмуртлар күбрәк Балтач, Кукмара районнарында яши. Шушы районнарның берсе «Удмурт сүзе» бәйгесен оештыруны үз өстенә алсын иде. Чүпрәле районы «Чуаш сүзе»н оештырырга риза булды, – диде Марат Әхмәтов. – Көндәлек матбугат турында берничә сүз әйтәсем килә. Республикада татар, рус басмаларыннан тыш башка милли басмалар аз. Удмурт газетасы нибары Балтач районында гына чыга. Аны 587 кеше яздыра. Һәр районга милли басма булдыру турында уйланырга киңәш итәм.

Республика мәктәпләрендә 100 туган тел кабинеты бар. Шуларның 15е – удмурт, 13е мари телләренә туры килә. Әлеге кабинетлар заманча әсбаплар, портретлар белән җиһазландырылган. «Без аларны тагын да баетырга риза. Әмма материалларны каян алырга икәнлеген белмибез. Күрше республикаларда әлеге мәсьәлә югары куелмаган. Әгәр Удмуртия, Мари Эл Республикасында мәктәп, бакча, клубларга кирәкле кызыклы, файдалы әйберләр булса, без сатып алырга риза. Тик кайдан алырга кирәклеген күрсәтегез», – диде комиссия рәисе.

Кукмара районы башлыгы Сергей Димитриев чыгышында удмурт, мари һәм башка милли телләрне өйрәнү өчен яшьләргә интернет каналлар кирәклеген әйтте. Ул шулай Кукмараның ничек итеп төрле милләтләрнең гореф-гадәтләрен, мәдәниятен саклавы турында да сөйләде. Монда һәр халыкның милли бәйрәмен үткәреп кенә калмыйча, авылларда милли үзәкләр дә булдырганнар. Мисал өчен, беренче булып Синерь авылында мари үзәге оешкан. Туристларны да шунда җәлеп итмәкчеләр.

Балтач, Әгерҗе районнарыннан килгән туган тел укытучылары укыту, тәрбия бирүдә үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Мари теленнән дәреслекләр булмавына зарландылар, милли лагерьлар кирәк дигән тәкъдимнәр җиткерүчеләр дә булды. Марат Әхмәтов һәр чыгыш ясаучыга, бу проблеманы хәл итү өчен нинди ярдәм кирәк, җитәкчеләр ничек булыша ала, дигән сорауны бирде. Менә бит нинди җылы мөнәсәбәт!

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының Милли мәгариф идарәсе җитәкчесе Илгиз Халиков һәр яңгыраган проблемага ачыклык кертте. Аның әйтүенчә, кызганыч, мари теле дәреслеге федераль исемлеккә кертелмәгән. Бу – зур фаҗига. Үз республикаларында мәсьәләгә салкын карыйлар. Андагы министрлыкка ихтыяҗ хакында җиткерелгән. Удмурт теленнән исә 22 дәреслек федераль исемлеккә кертелгән.

– Мәктәптә туган телләрне укытуны әти-әниләр сайлый. Әгәр без алар белән эшләмәсәк, беркем дә килеп гариза язмаячак. Аларны инандырырга кирәк. Быел 9 нчы сыйныф укучылары арасында туган телләрдән 2502 укучы имтихан сайлады. Узган елдан меңгә артыграк бу. Туган телдән имтиханны яхшы билгегә тапшырганда аттестатның уртача баллы да күтәрелә. Моның көллиятләргә укырга кергәндә файдасы бар. Әле берәүнең дә «2ле» алганы юк. Алар туган телен яхшы белә. Әлеге укучылар 11 нче сыйныфта бердәм республика имтиханы бирәчәк, ә бу – инде булачак укытучылар дигән сүз. Алар бит укып бетергәч, сезнең районга укытырга кайтачак, – диде Илгиз Халиков.

Бу урында ул берничә ел элек Кукмарадагы Ядегәр татар мәктәбен тәмамлаган, БДИдан 393 балл җыйган Инсаф Фәйзрахмановны да телгә алды. «Туган тел беркайчан да имтихан бирергә комачауламый. Без булган мөмкинлекләрне кулланырга тиеш», – диде Илгиз Халиков.

Һәр кечкенә милләт үзен зур халык итеп тоярга тиеш. Алар үзләрен ялгыз хис итмәсен, җитәкчеләр проблемаларга битараф калмасын. Утырышта менә шуңа игътибар зур иде.

– Бер ай вакыт эчендә аларның үтенечләрен төгәлрәк билгеләп, комиссиягә ниндидер эш планы булдырырга исәп. Бу зур финанс чыгымнар сорамый. Ихтыяҗлары зур түгел, әмма биредә кечкенә генә йогынты да аларга ышаныч тудырырга булышачак һәм нәтиҗәсе булырына ышанам, – дип йомгаклады сүзен Марат Әхмәтов.

Сәрия МИФТАХОВА

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ РАМИЛ ӘЙБӘТОВ:

«ЭШЛӘГӘН КЕШЕНЕ ЯРАТАМ»

Гамьле әңгәмә

Чирмешән районы үзгәрештә! Бер якта төзелеш бара, икенче якта юл ясыйлар. Бүген Чирмешән районы ничек яши? Авылларга яшьләр кайтырмы? Яңа башлык киләчәктә районны ничек итеп үзгәртергә тели? Шушы һәм башка яңалыклар турында хакимият башлыгы Рамил ӘЙБӘТОВ белән сөйләштек. Яңа җитәкченең әлеге вазыйфага билгеләнеп куелганына бер ел да юк әле. Районны өйрәнеп, кимчелекләрне барлап, хаталарны төзәткән чагы.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Рамил Тәлгатович, янәшәгезгә көчле команда туплагансыз. Кадрларны ничек сайлап аласыз? Булачак хезмәткәрнең нинди сыйфатларына игътибар итәсез?

– Беренчедән, мин кешене эшкә алганда, аның мәктәптә ничек укыганына игътибар итәм. Һәрвакыт аттестатын карыйм. Институтта ничәле алганы мөһим түгел. Ә менә мәктәптә куелган билгеләр аша кешенең тырышлыгын, үҗәтлеген белеп була. Акыллылар белән эшләү күпкә җиңел. Икенчедән, хезмәт кенәгәсенә күз ташлыйм. Ул – лакмус кәгазе белән бер. Кеше бер урында озак еллар эшләсә, димәк, аны курыкмыйча эшкә алырга була. Әгәр ул тегеннән монда күчеп йөри икән, ышаныч юк. Ул синдә дә озак эшләмәячәк. Моны үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Бервакыт бер бүлек җитәкчесенең сүзен тыңлап, андый кешене эшкә алдык. Нәкъ минемчә булды. Күчеп йөргән хезмәткәр монда да озак эшләмәде. Кайчак хаталар да кирәк. Шуларга карап, тәҗрибә туплыйсың.

:: Районга килгәч, иң элек нәрсәне үзгәртергә булдыгыз?

– Җитәкче итеп билгеләгәндә, районның хәле мактанырлык түгел иде. Район республикада авыл хуҗалыгы күрсәткечләре буенча – 33, спорт буенча – 41 нче урында. Шуларга игътибар иттем. Терлекчелекне алга җибәрү өчен шартлар, мөмкинлекләр кирәк. Спортта исә үҗәтлек, тырышлык белән зур үрләргә ирешергә була. Әнә шуны уйлап, спорт өлкәсендә шактый үзгәреш булды. Кайбер җитәкчеләр дә алышынды. Төптән тотындык. Эшләмичә генә бернигә дә ирешеп булмый. Спорт дигәннән, район халкына мөмкинлекләр булдырдык. Бассейнга һәркем йөри алсын дип, абонементлар керттек. Тирә-як районнардагы бәяне белештек тә бераз күтәрдек. Олыларга – 130, балаларга 20 сум иттек. Әгәр инде ай буена алдан алып куйсаң, бассейнда бер йөзгән өчен 83 сум гына түлисең. Әлбәттә, халык арзанракны сайлый. Бу инде ике якка да файдага.

Районда чисталык аксаган иде. Шуңа зур игътибар бирә башладык. Тәртип бәдрәфтән башлана дип уйлыйм. Районда экология буенча белгеч бар. Ул бар нәрсәне күзәтеп тора. Хәтта миңа да штраф сала ала. Миңа монда начар эшләргә ярамый. Чирмешән – минем туган җирем. Бәркәтәнеке мин.

:: Район балалары өчен җәйге лагерь ачкансыз икән. Киләчәктә бу юнәлештә тагынниләр эшләмәкче буласыз?

– Ул лагерь ташландык иде. Уйлаштык та, үз балаларыбыз өчен җәйге ял йорты ясарга булдык. Бар җитәкчеләр белән бергәләп тотынгач, бу лагерь тиз төзелде. Анда балалар өчен дә, яннарына килгән әти-әниләренә дә уңайлыклар тудырдык. Үзем дә барып күрдем. Бик матур урында урнашкан. Сабыйларның үз җирендә ял итүенә җитми инде! Киләчәктә без бу лагерьны ел әйләнәсе эшли торган итәргә җыенабыз. Моның өчен барлык шартлар да бар. Балалар – безнең киләчәк. Алар өчен башкарылган эшләр күп булырга тиеш.

:: Үз районыңа кайтып, җитәкче булып эшләү җиңелме, әллә киресенчәме?

– Төрле чаклар була. Мин бит бу вазыйфага үзем сорап килмәдем. Республика җитәкчелеге ышаныч белдергән икән, мин аны акларга тиеш. Юлсыз җиргә юл салу җиңел булмас. Әмма булдыра алганча, Чирмешәнем өчен тырышырмын. Шөкер, бер дулкында бергә эшләүче хезмәткәрләрем бар.

Районда эшлисе эшләр күп иде. Иң элек җирләрне арендага бирү мәсьәләсен катлауландырдык. Икенче төрле әйткәндә, тәртипкә салдык. Килешүгә җирне карап тоту, ашлау кебек шартлар керттек. Әгәр болар үтәлми икән, җирне кире алабыз. Һәрнәрсәнең хуҗасы булырга тиеш. Хуҗа булган җирдә генә тәртип бар. Яшермим, эшләгән кешене яратам. Андыйларга өстәмә премия дә кертелә. Районның һәр тармагы, шулай ук бюджеты да контрольдә булырга тиеш дип саныйм. Шулай эшләгәндә генә район алга китәчәк.

:: Чирмешәнгә туристларны җәлеп итәрсезме?

– Андый уй бар. Әмма иң элек күзгә ташланып торган кимчелекләрне төзәтергә кирәк. Татарстан Рәисе районга килгәч, иң проблемалы юллардан йөрдек. Ул үзәкне дә күрде. Әкренләп аны төзекләндерәбез. Мин эшкә килгәндә районны чүп баскан иде. Баксаң, дүрт район чүбен безгә ташлаганнар. Әкренләп бу проблема да хәл ителә. Мамадышка барып, чүп төяү станциясен карадык. Үзебездә дә шуны төземәкче булабыз. Тәртип булгач, курыкмыйча кунак чакырып була. Бездә тарихи урыннар да җитәрлек. Бер маршрут ясарга ният бар.

:: Авылларда хәлләр ничек? Аларның киләчәге бармы?

– Әле өмет бар. Авылларны ничек тә саклап калып булыр дип уйлыйм мин. Дөрес, өйдә бәдрәф ясап кына авылларга кеше кайтарып булмый, моның өчен матди ярдәм кирәк. Халыкка авылда яшәү отышлы булырга тиеш. Шәһәрдән күчеп кайтсыннар өчен махсус программалар кирәк. Әйтик, әгәр гаиләгә ай саен 15 мең сум күләмендә акчалата ярдәм була икән, әлбәттә, ул авылны сайлар иде. Авылда яшәүчеләр өчен ташламалар кирәк. Әйтик, ут өчен субсидия билгеләргә була. Авылларны колхозлар да саклар иде. Элек бит шулай булды. Районда 15 авыл хуҗалыгы оешмасы бар иде. Аларның һәрберсендә 100дән артык кеше эшләде. Менә сиңа 1500 кеше дигән сүз. Колхоз бетүгә бөтен система җимерелде. Элек авыл хуҗалыгының һәр юнәлешендә фәнни үзәк бар иде. Бөтен әйбер планлаштырылып эшләнде. Дәүләтнең күпме ашлык сатып аласы да билгеле иде. Әнә шул системага салу җитми.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыятенең мич чыгаручысы **Мальцев** Николай Иванович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгы урынбасары **Гәрәева** Гүзәл Рифкать кызы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Гафиятуллина** Рәхилә Шамил кызы, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Мөбинов** Илдар Вакыйф улы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы **Мөхәммәтҗанов** Илгизәр Мәгъсүм улы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге баш белгече **Нуриева** Сания Абдулла кызы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Биклән авыл җирлеге башлыгы **Сәхбиев** Мансур Шакирҗан улы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Фаизов** Вәзир Назирьян улы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Шаһиева** Рәисә Гомәр кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Әхмәтов** Ирек Мәхмүт улы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе контроль бүлеге баш киңәшчесе **Гыйниятова** Гүзәл Җәүдәт кызы, Татарстан Республикасының «Шәһәр яны укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе проект инженеры **Зарипов** Илгиз Нәҗип улы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Эшләр идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чараларына хезмәт күрсәтү һәм аның биналарын карап тоту бүлекчәсе өлкән белгече **Ильясова** Гөлсәйдә Хатыйб кызы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире **Кузьмина** Елена Викторовна, хезмәт ветераны **Мөбарәкҗанов** Рәис Сәхип улы, хезмәт ветераны **Сәетов** Разил Сәетмөхәмәт улы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Хантимеров** Илнар Миннеилдархан улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыяте слесаре-сантехнигы **Ильин** Михаил Васильевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: катлы камыр ризыклары цехы мастеры **Гайсина** Мәдинә Таҗи кызына, камыр куючы **Маратаева** Елена Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Ватан хакына

ЫШАНЫРГА КИРӘК...

Бәйрәмнәрдә – кадерле кунак, яшьләр өчен – үрнәк... Махсус хәрби операция зонасыннан вакытлыча туган якларына кайткан батыр егетләр белән очрашу сәгатьләре бик чикле. Шулай да районнарда аларның хәлләрен белешергә дә, бәйрәмнәрдә күңелләрен күтәрергә дә, яшьләр белән очраштырырга да өлгерәләр.

Шактый районнарда ялга кайткан егетләр белән очрашу чәй табыны янында уза. Алар белән иркенләп, өйдәге кебек мохиттә сөйләшәсебез килә, ди район башлыклары. Әгерҗе районының башкарма комитеты җитәкчесе Ленар Нургаянов та ялга кайткан хәрбиләр белән чәйле өстәл янында сөйләшкән, аларны борчыган проблемаларны белешкән.

– Сигез ай сизелмичә узып китте. Өйдәгеләр бик сагындырган инде. Алар белән озаграк буласы килә, – дигән хәрбиләр.

Очрашуга ике үсмер улы белән килгән ир-ат, балалардан килгән хатларны аеруча кадерләп саклыйбыз, дип уртаклашкан.

– Күзләргә яшьләр тула. Укыгач, кадерле урында саклыйбыз без аларны. Мондый хатлар рухны күтәрергә сәләтле бит... – дигән ул.

Нурлатта исә ялга кайткан хәрбиләр чуашларның милли бәйрәме – Уявның кадерле кунаклары булган. Күңел ачу чараларында катнашу белән берраттән, солдатлар бәйрәм мәйданындагы «Сугышчан туганлык» почмагында кунаклар белән аралашкан, махсус хәрби операция зонасыннан алып кайтылган машина турында сөйләгән. Алар янында халыкның аеруча күп булуын әйтеп торасы да түгелдер инде. Барысы да батыр райондашлары белән очрашып, сөйләшеп, хәлләрен белешеп калырга ашыккан. Өстәвенә шушында ук солдат боткасы, борщ һәм тушенка авыз итеп карарга мөмкин булган.

Мамадыш районының «Берсут» лагеренда ял итүче яшь спортчылар, аеруча «Спарта» боксчылар клубында шөгыльләнүчеләр бу сменаларын әле озак кына хәтерләрендә саклар. Ник дигәндә, лагерьга үз теләге белән махсус хәрби операция зонасына китеп, хәзерге вакытта ялда булучы тренерлары килгән бит! Күптән көтелгән әлеге очрашуда рәхәтләнеп сөйләшкән алар.

– Махсус хәрби операция зонасында якын дустым һәлак булды. Анда барырга әнә шул кайгылы хәбәр этәрде. Инде карар кылгач, мине барысы да калырга үгетли башлады. Нәрсәгә ул, кирәкми ул сиңа, диештеләр. Тормышымны бокс белән бәйләргә ниятләп йөргәндә дә ишетергә туры килде миңа бу сүзләрне. Ләкин мин үз сүземдә калдым, – дип сөйләгән ул яшь егет-кызларга.

«Спарта» боксчылары тренеры хәрби операция зонасына 10 ел элек армиядә хезмәт иткән иптәшләре белән бергә киткән. Чара барышында яшь спортчылар хөрмәтле кунакны операциядә катнашу, фронт яны территорияләрендә тыныч халыкның тормышы турындагы сорауларга «күмде».

Сүз уңаеннан, тренерлары махсус хәрби операция зонасына киткәч, «Спарта» боксчылары «Ярдәм янәшә!» хәрәкәтендә волонтер булып эшли башлаган. Билгеле, хәрби бурычларын үтәүче тренерлары бу яңалыкка битараф калмаган. «Гуманитар ярдәм җыюда катнашып, үз өлешегезне кертүегез өчен ихластан рәхмәт сезгә!» – дигән ул.

Хәрби операция зонасыннан ялга кайткан егетләр арасында гаилә корып калырга ашыгучылар турында әледән-әле хәбәрләр килеп тора. Әйтик, шушы арада гына Чүпрәле ЗАГСында ялга кайткан Динар сөйгәне Снежана белән никахларын теркәгән.

Динар махсус хәрби операция зонасына 2022 елның көзендә – өлешчә мобилизация башлангач китә. Туган ягында аны якыннары һәм сөйгәне Снежана зарыгып көтә. Мәңге бергә булырга вәгъдәләшкән пар күптәнге хыялларын Динар ялга кайтуга чынга ашыра.

Яшьләрнең язылышу тантанасында Чүпрәле районы башлыгы Марат Гафаров та катнашкан. «Ак бәхетләр һәм тиз арада яңадан кавышуыгызны телим!» – дип котлаган ул, яшь гаиләгә истәлекле бүләкләр тапшырып.

Динар белән Снежанага ширбәт айларын берникадәр вакытка кичектереп торырга туры килә. Динар инде янәдән хәрби операция зонасына киткән. Ләкин яшьләр бары яхшыга гына өметләнә. «Иң мөһиме – ышанырга кирәк!» – ди алар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЕРТЫК ҖИЛКӘННӘР

Премьера

Рокыя – телсез, сәхнә – бер үк вакытта фатир да, поезд да, бертуктаусыз әйләнеп торган вакыйгалар күчәре дә. Тинчурин театры сезон ябылышы уңаеннан, гадәттәгечә, яңа спектакль чыгарды. Театр труппасы Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр»ен сәхнәләштерде. Көлдерме торган комедия итеп.

«Татар-информ»

Тарих

«Җилкәнсезләр»не Кәрим Тинчурин язып кына калмыйча, үзе сәхнәгә чыгара, уйный да. 1958 елда әлеге әсәрне Ширияздан Сарымсаков сәхнәләштерә. Пьесаны 2004 елда Тинчурин театрында да уйныйлар. 2016 елда «Җилкәнсезләр»не Камал театрында куялар. 2018 елда әлеге спектакль репертуардан алына.

Камалда куелганының «Киләчәк турында хатирә» дигән өстәмә исеме дә бар иде әле. Хәер, Тинчуриндагы премьераны карагач та, бар да һаман шул, бу сүзләрне аларга да кулланып була икән дигән фикергә киләсең. Ә бит әсәрдә сүз 1910–1925 еллар, шул чорның яшен тизлегедәй үзгәреп торган вакыйгалары турында бара.

Тамаша

«Җилкәнсезләр» – интерактив спектакль. Ягъни биредә тамашачы да – азмы-күпме актер. Тамашачылар, артистлар белән бергә, ике сәгатькә шул чорның үзгәрешләре боҗрасында кала. Спектакль алдыннан: «Урыннардан тору, чыгып китү тыела», – дип юкка гына кисәтмиләр инде, димәк. Чөнки тамашадагы хәлләрдән тиз генә котылам димә. Үзгәрешләрдән качып китеп тә, күзне йомып, күрмәмешкә салышып та булмый. Сәхнәдә артистлар тудырган образлар качарга, китәргә тырышса да.

Тамашачы спектакльдә күзәтүче буларак кына түгел, катнашу өчен дә кирәк. Әйтик, тамашада байлардан акча сорау өлеше бар. Мисбах хаҗи (Зөфәр Харисов): «Безне генә саварга димәгән...» – дип, халыктан да, ягъни тамашачыдан да акча җыярга өнди. Сүз уңаеннан, «милләт файдасына» дигән «банк»ка акча салучылар булды залда. «Җилкәнсезләр»нең режиссеры Туфан Имаметдинов, уенын-чынын бергә кушып, җыелган акчаның чынлап та «милләт файдасына» тотылачагына ышандырды.

Спектакльдә образлар күзгә күренеп, вакыйгалар куерган саен, үзгәрә. Әллә кем булган байлар (Ирек Хафизов, Зөфәр Харисов) яңа җәмгыятьтә бөлә, белемле, зыялы яшьләрнең (Илнур Байназаров) зур җирләрдә алган белемнәре бу җәмгыять өчен ят, төптәгеләр, бер мәртәбә акча тәмен татый алганнар (Рөстәм Гайзуллин) – алгы сафта. Турысын бәреп әйтә торган Рокыя (Венера Низамова) гына үзгәрми. Сүз уңаеннан, режиссер аны сәхнәгә телсез итеп чыгара. Ул ишарәләр белән генә аралаша. Аның: «Һаман сүз, күмер юк, күмер кирәк!», «Телеңне ломбардка салдың әллә?», «Кая синең хөрриятең, иттифагың? Кая милли шураң? Кая халкың? Дәүләтең? Телең?» дип «кычкырулары» бигрәк тә күңелгә тия. Телсез кызның җан авазы ныграк ишетелә спектакльдә. Сорауларга җавап кына юк... Ә сәхнә әйләнә. Тормышның үзе кебек. Түгәрәкнең очы-кырые юк бит. Димәк, бар да кабатлана...

Туфан ИМАМЕТДИНОВ, Тинчурин театры баш режиссеры:

– «Җилкәнсезләр»дә гаҗәеп чор сурәтләнә. Һәр иртәдә яңа илдә уянасың сыман. Хәзер дә шулай бит. Бер нәрсәгә дә ышанып булмый. «Җилкәнсезләр»дә дә – шул ук хәл. Әйтик, анда Мисбах Батырханга ышанмый. Геройлар үзен ничек тотарга белми. Билгесезлек. Тинчурин да теләгән бөтен нәрсәсен яза алмагандыр. Шуңа аның баш герое – Батырхан – бер үк вакытта драматик образ һәм аферист та.

Ирек ХАФИЗОВ, актер (Нуретдин ролен башкара):

– «Җилкәнсезләр» – Кәрим Тинчуринның үлмәс әсәре. Безнең аңа кире әйләнеп кайтуыбыз юкка түгел. Әсәр бүгенге вазгыятькә аваздаш. Спектакльдә элеккеге татар байлары, зыялыларның нинди эшләр башкарып йөргәнен күрәчәксез. Образымның характерына килсәк, бәлки, Нуретдинның сыйфатлары Иректә дә бардыр. Тормышта сөйкемле генә күренсәм дә, усаллана да беләм.

Артем ПИСКУНОВ, актер (Батырхан ролен башкара):

– «Җилкәнсезләр» – бөек әсәр, Тинчуринның иң көчле пьесаларының берсе. Ул һәрвакыт актуаль булачак. Милләт мәсьәләсе, кешеләрнең тарихи вакыйгаларга баш имәве һәм баш июе, елгага каршы йөзүе яисә елга белән бергә агуы турында ул. Татар халкы өчен милләт проблемасы һәрвакыт беренче урында булды. «Җилкәнсезләр»не төрле жанрда куярга була. Еллар буе казынсаң да, әллә ниләр чыгарырга мөмкиндер аннан. Камал театры бу әсәрне үзенчә күргәндер, бездә куелганы – башкача. Әсәрдә икенче пландагы рольләр юк. Барысы да – язмышлар. Һәр образ – халыкның бер пласты.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

Камил КӘРИМОВ, язучы:

– Бәхет ул – бәхетсезлек булмаган чор.

«Үпкәсез туй»

БУЛАТ БӘЙРӘМОВ УТСЫЗ ТУЙНЫ УТ ИТКӘН

Булат Бәйрәмов туй-мәҗлесләр үткәрү белән күптәннән шөгыльләнә. Гадәттә, хатыны, популяр җырчы Ләйсән Гыймаева белән бергә эшлиләр. Йөри торгач, кызыклы хәлләр дә килеп чыккалый. Әле тамадалык эшенең чишмә башында Самара якларына барганнар. Гадәттә, чарага ярты сәгать алдан килә алар, әзер булырга шул җитә, ди. Әмма бу юлы ерак җир булгач, бераз алданрак килергә булганнар. Килсәләр, алар белән бергә бер-бер артлы кунаклар җыела башлый. «Ник иртә килә икән болар», – дип уйлап куя Булат. Баксаң, Самара вакыты бер сәгатькә алда икән! «Ярый әле, вакытлырак чыкканбыз», – ди Булат. Әмма маҗара моның белән генә бетми. Туйны башлаулары була – ут бетә! Инде нишләргә? Булат ике дә уйламый, кунакларны ресторан каршындагы мәйданга чакырып чыгара. Ди-джее баян чыгарып, кунакларны биетә башлыйлар. Утны бер сәгатьтән соң гына бирәләр. Һәм туй дәвам итә.

Тагын бер хәлне искә төшерде Булат. Әле күптән түгел генә булган туй. Кәләшнең әнисе бик яшь, мөгаен, 18 яшьләрдә бала тапкандыр. Кунаклар исемлегенә ышансың, каядыр шушы тирәдә кәләшнең сеңлесе дә булырга тиеш. Булат микрофон белән чараны башлап җибәрә. «Күрегез әле, кәләшнең сеңлесе ничек игътибарлы, апасының чәчләрен, фатасын тигезләп тора», – дип соклана тамада. Теге хатынның күзе шар була. «Мин аның сеңлесе түгел, мин – аның әнисе!» – дип әйтеп куймасынмы?! Булат уңайсызланып куя. «Алар өчесе дә бер-берсенә охшаганнар, барысы да ябык комплектациядә, – дип сөйләде Булат «Ха-ха-ханә»гә. – Аннары бит косметология дә бик алга китте. Кем әни, кем апа, кем сеңел – аңламассың да!» Менә шундый «Санта-Барбара».

Әз-мәз мәзәк

Базарда урам себеркесе сатып алган идем. Троллейбуста барам. Бер егет миңа карады да сорап куйды: «Бүген кабынмадымы әллә?»

* * *

«Менә бу ароматның ноталарын тыңлап карагыз әле», – диде миңа парфюмерия сатучы кыз. Сул як колагыма куйдым, уң як колагыма куйдым – берни ишетмәдем.

* * *

Ул шулхәтле явыз кеше иде: күлдә үрдәкләр ашатканда да аларның башларына кизәнә иде.

* * *

– Югары белемле кешеме син? Ә, бәлки, ике югары белемең бардыр? Балаң белән өй эше эшләп кара.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Кызык-мызык

Ну, була бит инде шундый кешеләр, юморны аңламый торган. Берничек тә. Менә бу кешеләр юморны аңламый, ә юмор аларны аңлый. Һәм һәртөрле кызыклы хәлләр нәкъ менә шундый кешеләргә ияреп йөри.

Әнә шундыйрак бер таныш бар минем. Яхшы күңелле, әйбәт кеше. Тик җитди. Бик җитди. Ә кызык хәлләр үзенең билбавына ябышып йөри.

Яшь чагында ук әле... Бер кызга гашыйк була, йөри башлыйлар. Кыз әтисе белән генә яши. Әтисе бик еш командировкага китә. Үзе юкта күз-колак булып торырга күршеләрен яллый. Ну, күршеләр – текә инде. Подъезд алдында утырган әбиләрдән башлап, барысы да күз-колак була.

Вәт, бер мәлне әтисе командировкага китүгә, кыз егеткә шалтырата. Егет килә. Тик сиздермичә генә фатирга үтү җае юк. Подъезд алдында утырган әби-чәби шундук әтисенә хәбәр итәчәк, әтисе кызны тиргәячәк. Фатирлары беренче катта гына булгач, бу балкон аша керергә була.

Дәрте ташып торган егеткә авыр нәрсә түгел – керә бу. Кыз табын әзерләгән, бераз капкалап алалар... Шуннан кочаклашу... Кысыбрак кочаклашырга гына җыенып беткәч, ишектә кыңгырау чылтырый. Берәр күрше карчыгыдыр дип барып ачсалар, өй эченә милиция керер тула.

Бактисәң, егетнең балкон аша кергәнен бер карчык күреп калган икән. Моны карак дип уйлап, тәртип сакчыларын чакырган. Һәм әле дә: «Менә шушы карак», – дип басып тора. Өстәвенә, күз дә йоммыйча: «Бу минем дә балконга кергән иде, бөтен чүпрәкләрне урлап качты», – ди. Ярый кыз сабыр булып чыга, барысын да тыныч кына аңлатып бирә. Шулай котылып калалар.



КӘМИТ

Өйләнешәләр болар. Бер-бер артлы кызлары туа. Әти-әниләре эштә чакта кызлар качышлы уйнарга күнегеп китә. Шкафка яшеренәләр. Әниләре кайтуга, бөтен дөньяны туздырып бетерәләр. Көн саен. Моңа ничек чик куярга белмәгән әниләре хәйлә кора:

– Кызым, сез шкафка кермәгез, анда мыеклы усал абый бар, – дип кисәтә.

Кызлар чынлап та шкафны туздырмый башлый. Тынычланалар. Ә көннәрнең берендә, җыелышып кичке табында утырганда, өлкәнрәк кызлары шыпырт кына сорап куя:

– Әни, ә шкафтагы теге мыеклы абый киттеме әле?

Ә ир җитди. Бу сүздән соң кара коелып төшә. Һәм хатынына бик озак, бик тырышып акланырга туры килә. Ләкин икенче көнне үк тагын көтелмәгән хәл килеп чыга. Ничектер йолдызнамәләр турында сөйләшеп китәләр дә кызлары сорап куя:

– Әни, ә син кем йолдызнамә буенча?

– Кыз.

– Ә мин кем? Ә син бер хәрефен генә әйт, калганын үзем табам.

– К...

– Кысла! – Кыз кулларын кыскыч итеп суза. – Мин – Кысла... Ә әти кем?

– Б...

– Болан! – ди кыз, шатланып, һәм кулларын тармаклы мөгез итеп баш өстенә куя. – Безнең әти – болан!

– Юк, кызым, болан түгел, ә Балык... – Кичә генә шкафта мыеклы абый юклыгын исбатлап аптыраган хатын дулкынлана төшә. Ә кызга аның халәте мөһим түгел, аның үз уены – уен:

– Балык. Мөгезле балык, әйеме. Безнең әти – Балык...

Ә ир җитди. Ул кара көеп хатынына бераз карап тора да ишекне шапылдатып чыгып китә. Ишегалдын әйләнеп килә дә подъезд алдында утырган әбиләр янына туктап, акрын гына сораштырмакчы була:

– Карале, безгә нинди мыеклы ир килгән иде ул?

Әбиләр бер-берсенә карашып ала. Әйтерлек бер сүзләре дә юк. Шунда берсе шаяртырга уйлый:

– Ә син баягы ирне әйтәсеңдер әле. Син чыгып китү белән кереп китте бит...

Ир шундук күздән югала. Йортына атылып керә. Бүлмәләрне, балконны, шкафларны тикшереп чыга. Билгеле инде, беркем дә юк. Шуннан бу бушап калган өстәл янына барып утыра. Җитди итеп уйлана, анализлый. Һәм берзаман шаркылдап көлеп җибәрә. Шатлыктан да, әлбәттә, әлеге күренешнең кәмитлеген аңлаудан да.

Марат КӘБИРОВ

Биби һәм ЮХИДИ

«10 ел рульгә утырмаган идем, – ди Биби. – Бүген беренче тапкыр юлга чыктым. Бөтен кеше миңа сигнал бирә, фараларын яндырып ала, кулларын болгый. Сагынганнар!»

ЮХИДИ хезмәткәре протоколыннан:

– Дин әһеле миңа ришвәт бирергә җыенгач, мин бармак белән өскә күрсәттем дә: «Ул барын да күрә», – дидем. Дин әһеле багана башындагы видеокамерага карады да акчасын кесәсенә кире алып куйды.

– Әти, сиңа караганда әни машинаны остарак йөртә.

– Ник алай дисең, улым?

– Син 12 чакрымны «ручник» тормозы белән уза алмас идең.

Мин утырган таксиның йөртүчесен ЮХИДИ хезмәткәре туктатты. Аны машинада көтеп утырганда таныш хис искә төште. Балачакта дустым өенә кергәч, аңа әти-әнисе кычкырганда, шулай сабыр гына көтеп утыра идем.

ЮХИДИ хезмәткәре:

– Сезнең бу правагыз дөрес түгел.

– Ник?

– Карагыз фотосын.

– Нәрсә булган фотога? Әнә сулдан өченчесе – мин.

– Алло, кадерлем, балкон тәрәзәсеннән кара әле, мин машинаны юл кырыена дөрес туктаттыммы?

– Сул як кырыенамы, уң як кырыенамы?

ИЛСӨЯ БӘДРЕТДИНОВА ҺӘМ «ЙӘ» СҮЗЕНЕҢ КӨЧЕ

Татарда бик көчле бер сүз бар. «Йә» сүзе. Нибары ике хәреф. Ситуациясенә һәм интонациясенә карап, ул бик күп нәрсәне аңлатырга мөмкин: сорау, өндәү, орышу, ишарә, ризасызлык, үтенеч, хуплау, каршы килү һ.б. Ә иң кызыгы, ул капма-каршы мәгънәләрдә кулланылырга мөмкин. Бу сүзнең ачысын һәм төчесен популяр җырчы, үзе әйтмешли, «атказанмаган артист» Илсөя Бәдретдинова үз җилкәсендә татыган. Берсендә ул безгә болай дип сөйләгән иде. Бала кеше әти-әнисеннән тегене-моны сорый бит инде. Илсөя дә нормаль бала булган. Әти-әнисенең җиңеннән гел тартып торган. «Әтиең кайткач, әтиеңнән сорарсың», – дип әйтә торган булган әнисе. Илсөя әтисе кайтканын көткән. Әмма әтисенең кызы соравына җавабы гел бер була: «Йә!» Әти кеше уенда бу сүз «ярар» дигәнне дә аңлаткан, «юк, бәйләнмә әле» дигәнрәк төсмердә дә кулланылган. Шуңа күрә «Йә!» дигән җаваптан кечкенә Илсөя гел югалып кала торган була. Кызык хатирә, әйеме? Ошадымы, йә?

ХУШ КИЛӘСЕҢ, ИЮЛЬ!

Июльгә минем планнар: июньдә эшләп бетерергә өлгермәгәнне эшләп бетерергә.

Элек мин җәйне ярата идем. Ә хәзер акчаң булса, җәйне теләсә кайсы вакытта оештырып була. Хәзер мин акча яратам.

Июльдә шәп итеп кызынырга мөмкин! Эшкә барган арада.

Безнең дуслар арасында матур гадәт бар: һәр ел саен июль аенда гаиләләребез белән берәр кая ялга барырга җыенабыз һәм бармыйбыз.

Җәй көне 40 минут йөгерү 5 минутка гомерне озынайта, дип исәпләп чыгарган галимнәр. 35 минут вакытыбыз эрәгә уза булып чыга түгелме?

– Әмир, син мәктәпне ни өчен яратасың?

– Июнь, июль һәм август айлары өчен.

– Туган көнегезне әйтегез.

– 1 июль.

– Ничәнче ел?

– Ел саен.

Өйдә буран булмасын

Гаепле хатыннан ничек гафу үтенергә, өйрәтегез әле?

* * *

– Әйе, мин хаклы түгел идем! Әмма моңа син гаепле!

* * *

Хатыныңны яратсаң, аның өй буйлап таралган чәчләрен дә ярат.

* * *

– Матурым, тоз чәчелде, димәк, өйдә тавыш чыгачак.

– Алдан ук начарга юрама әле.

– Юк, мин үземне инде әзерләдем.

* * *

– Бар, ботка аша.

– Син бит аш пешерә башлаган идең?

– Башлаганда аш иде.

* * *

Гаиләдә хатын ул – иргә проблемаларны хәл итәргә булышучы кеше. Дөрес, өйләнмәгән булса,

ир бу проблемалар турында ишетеп тә белмәс иде.

* * *

Бу синең кеше түгел икәнне аңлар өчен, 5 минут вакыт җитә. Точно синеке түгел икәнне аңлар өчен, тагын 10 ел кирәк.

АКЧАҢ БУЛСЫН БЕР БУКЧА

Әйбәт акча эшләр өчен әйбәт акча эшләүчеләрне җитәкли башларга кирәк.

– Финанс хәлегез?
– Бер сүз белән әйткәндә: минем белән дус булучылар акча өчен йөрми.

– Без, ниһаять, акча җыйдык һәм ремонтка тотындык.
– Нәрсәдән башладыгыз?
– Талаштан.

– Безнең арада булган бар нәрсәне оныт!
– Ә минем исемгә алган кредитыңны?
– Анысын да.

Кызлар, Шанель һәм Диор букчалары – чүп ул. Иң шәбе – инкассатор букчасы.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 292

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+